КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 апрель г.Казань № 387

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турында» 2016 ел, 28 июль, 524 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 7 апрель, 218 нче; 2018 ел, 14 май, 358 нче; 2019 ел, 15 апрель, 293 нче; 2020 ел, 11 апрель, 274 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның» сүзләрен «дәүләткә карамаган оешмаларның» сүзләренә, «ала алуын оештыру» сүзләрен «этаплап ала алуын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

преамбуланы, 1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын этаплап ала алуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет

акчасын этаплап ала алуын тәэмин итү буенча координация советы (алга таба – Координация советы) төзергә.

2. Бу карарга теркәлгән Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын этаплап ала алуын тәэмин итү буенча координация советы турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын 2025 елга кадәр эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын этаплап ала алуын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының комплекслы планын эшләү өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы итеп билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы турындагы нигезләмәдә:

исемендә татар текстында «социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның» сүзләрен «дәүләткә карамаган оешмаларның» сүзләренә, «ала алуын оештыру» сүзләрен «этаплап ала алуын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмәдә Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын этаплап ала алуын тәэмин итү буенча координация советы (алга таба – Координация советы) эшчәнлеген оештыру тәртибе билгеләнә.»;

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елга кадәр эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган оешмаларның халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын этаплап ала алуын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасының комплекслы планын (алга таба – Татарстан Республикасының комплекслы планы) эшләү;»;

әлеге карар белән расланган Эшчәнлекләрен социаль өлкәдә гамәлгә ашыручы социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның халыкка социаль хезмәт күрсәтүгә бүлеп бирелә торган бюджет акчасын ала алуын оештыру буенча координация советы составында:

исемендә татар текстында «социаль юнәлеш алган коммерциячел булмаган оешмаларның» сүзләрен «дәүләткә карамаган оешмаларның» сүзләренә, «ала алуын оештыру» сүзләрен «этаплап ала алуын тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

Координация советы составыннан А.М.Минголовны, А.А.Сабированы, Р.Н.Садыйковны, Л.М.Сәетованы һәм А.Р. Шәрәповны чыгарырга;

Координация советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментына караган Гражданлык җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итү идарәсенең иҗтимагый-сәяси һәм коммерциягә карамаган оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлеге баш киңәшчесе Марина Николаевна Лукашинаны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының дәүләт тармак программаларын гамәлгә ашыру һәм үстерү бүлеге башлыгы Владислав Викторович Усановны;

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары Рамил Камил улы Хәйруллинны;

Татарстан Республикасы спорт министры урынбасары Алмаз Әзһәр улы Хөсәеновны;

Пелевин Олег Владимировичның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары, Координация советы рәисе урынбасары»;

Антон Георгиевич Дыгановның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы эксперты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Инновацион үсеш идарәсе башлыгы (килешү буенча)»;

Любовь Николаевна Мишинаның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы эксперты, «Россия пенсионерлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге идарәсе рәисе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин